ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 п.г.т. Алексеевское № 489

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 19.04.2022 №137 «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Федераль әһәмияттәге шәһәр Мәскәүдә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында (Татарстан) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.03.2019 № 322 «Субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган грантлар бирү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»карары нигезендә

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 19.04.2022 №137 «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында»гы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кушымта №1 нең 1.4 пунктның 2 абзацын алдагы редакциядә бәян итәргә:

«- грантлар алу хокукына конкурс үткәрүне елга 2 тапкыр гына оештыра;»;

1.2. Кушымта №1 нең 3.3 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«-Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан агымдагы календарь елда «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга бирелгән грант (субсидия рәвешендәге грант) җиңүчесе түгел;»;

1.3. Кушымта № 1 нең 6.3 пунктның 5 абзацын алдагы редакциядә бәян

итәргә:

«- продукция житештерү яки хезмәт күрсәтү өчен кирәкле комплектлаучы өлешләргә түләү;».

1.4. Кушымта № 1 нең 6.4 пунктын алдагы редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 229 статьясындагы 1 пункты нигезендә грантлар (грантлар рәвешендәге субсидияләр) җыючылар, грант алынган салым чорыннан соң киләсе елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, салым декларациясен тапшырырга тиеш.».

2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 19.04.2022 №137 «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында»гы карарының 3 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

сүзләр: «Ястребова Т.А. – Татарстан Республикасы буенча эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил каршындагы җәмәгать вәкиле (килештерү буенча)» сүзләренә алмаштырырга: «Куприянова Т.В – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы»;

сүзләр: «Голубев Р. В - Алексеевск районында эшчәнлек алып баручы шәхси эшмәкәр (килештерү буенча)» сүзләренә алмаштырырга: «Голубева О.М. - Алексеевск районында эшчәнлек алып баручы шәхси эшмәкәр (килештерү буенча)».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**